Шәһәр күләмендә математика фәненнән татар телендә үткәрелә торган олимпиаданың йомгаклау этабы биремнәре
2023-2024 нче уку елы
8 нче сыйныф

Эш вакыты – 180 минут
Гомуми балл – 25

1. Төгәл 48 кисешү ноктасы килеп чыгарлык итеп 12 туры уздырыгыз.

2. 999 919 саны гади сан булып торамы? Нәкъ ике бүлүчесе булган натураль сан - гади сан дип атала. Беренчесе ул үзе, ә икенчесе берле саны.

3. ABC өчпочмагында CH биеклеге уздырылган. $AB = 2CH$, $\angle A = 30°$ булуы билгеле. C почмагының зурлыгын табыгыз.

4. $4x^2 + 9 \geq 12x$ тигезсезлеген исбатлагыз.

5. Студентлар төркеме фильмны бергәләп карау өчен кинозалны арендага алырга җыенган. Аренда бәясе 170 евродан 195 еврога кадәр торган, һәрберсе бертигез бәяне түләргә тиеш булган. Ике студент авырып китү сәбәпле килә алмаган. Шуңа күрә калганнарга 1 еврога артыграк түләргә туры килгән. Залны арендага алу бәясе күпме торган?